ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_14.11.2022_ Мөслим авылы № _659_

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 2021 елның 22 декабрендәге 627 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 22 декабрендәге 627 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга түбәндәге эчтәлекле 3.4 пункт өстәргә:

«Урта гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларын ике тапкыр түләүсез кайнар ризык белән; Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының төп һәм башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәт узучы гражданнарның гаиләләреннән 1-9 класс укучыларын бушлай кайнар ризык белән туклануларын тәэмин итәргә».

2. Күрсәтелгән ташламаны, хәрби комиссариатның өлешчә мобилизация кысаларында гомуми белем бирү оешмасында укучының ата-анасын (законлы вәкилен) хәрби хезмәткә чакыруы турындагы белешмәсе нигезендә бирергә.

3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренең укучы балаларын бушлай тукландыруны финанслауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның 3.4 пунктчасының гамәлдә булуы имза салынган вакыттан үз көченә керә һәм гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу чорына билгеләнә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның социаль-мәдәни үсеш буенча җитәкчесе урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**